## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**12 ноябрь 2025 ел** **№ 2**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлеге составына керүче Түбән Чыршылы авылында 2026 елда үзара салым кертү турында

2025 елнын 20 мартындагы «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 маддәсе, 28.07.2004 №45-ТРЗ Татарстан Республикасы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы законының 35 статьясы нигезендә, Сарман муниципаль районының Югары Чыршылы авыл җирлеге Уставының 18.1 маддәсенә таянып, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлегенең Түбән Чыршылы торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлеге Түбән Чыршылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 нче төркем инвалидларыннан, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнардан, мобилизацияләнгән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, көндезге уку йортлары студентларыннан тыш, 2026 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

1) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тору (Түбән Чыршылы торак пунктында юлларны кардан чистарту (шартнамә буенча йөртүче эшләре һәм хезмәт күрсәтүләре өчен түләү); (Түбән Чыршылы торак пунктында җирлек Юлы эчендә ремонтлау (ташу, вак таш салу, шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

2) торак пункт территориясен төзекләндерү (торак пункт территориясен чабу (шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү): трактор тоту (Беларус МТЗ 82.1 тракторы өчен ягулык-майлау материаллары, запас частьләр, чыгым материаллары сатып алу); Түбән Чыршылы торак пунктында);

3) Түбән Чыршылы торак пунктындагы урамнарны яктырту өчен светодиодлы лампалар сатып алу һәм урнаштыру.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Югары Чыршылы авыл җирлеге Советының мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән,Татарстан Республикасы хокукый мәгълумат рәсми порталында http: //pravo.tatarstan.ru., Сарман муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында http: //sarman.tatarstan.ru. кабул ителгәннән соң җиде көн эчендә бастырып чыгарырга.

Халык җыенында рәислек итүче
Сарман муниципаль районы
Югары Чыршылы авыл җирлеге башлыгы Гилева Р.М.Гилева